Татарстан Республикасы  Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле гомуми урта белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе

# “Салют, Пионерия” бәйгесе-акциясе

2017 ел

Балалар оешмасы-иҗтимагый мәктәп ул. Анда катнашу буш вакытны файдалы һәм кызыклы итеп үткәрергә, шәхес буларак танылырга ярдәм итә. 3 эзтабар, 3 варис һәм 3 остазлар отрядын берләштергән “Таң" балалар оешмасы “Һәр көнне игелекле эш!”-девизы астында яши.

Быел Пионериянең 95 еллыгына багышланган «Салют, Пионерия» бәйгесе – акциясе уңаеннан безнең оешмада байтак эшләр башкарылды. Мәктәп музееын балалар хәрәкәте тарихына багышланган стендлар белән тулыландырдык. «Таң» оешмасы активы белән истәлекле символикалар ясадык. Мәктәп территориясенә пионер бердәмлеге аллеясе ясап нарат һәм чыршы үсентеләре утырттык. Озак еллар вожатый булып эшләүче Курмаева Рәшидә Нәбиулла кызы, пионер-ветераннар (40нчы-80нче еллардагы) Амирова Гаян апа, Калимуллин Наил абый, Амиров Рөстәм, Заббарова Алияләр белән очрашулар үткәрдек.

Әңгәмәләребез бик кызык үтте. Һәркайсының хатирәләре бик җылы иде. Ул елларын бик сагынып сөйләделәр. «Урта Тигәнәле авылында балалар хәрәкәте тарихы» дигән эзләнү эшен алып бардык. «Пионер тарихы эзеннән» дигән елъязма төзедек.

# “Салют,пионерия!” бәйге акциясе



Пионер бердәмлеге аллеясе

# Мәктәп музеенда безнең тарих



# Пионер хәрәкәте ветераннары



# Истәлек символика






# Видеоязмалар